# КҮКНЕҢ ҖИДЕНЧЕ КАТЫНДА





## 1 сентябрь – Белем көне

**СОКОЛОВА СОФИЯ**

Тәүге мәртәбә туган илнең һәр шәһәрендә, районында, авылында 1 нче сентябрь- Белем бәйрәмен каршы алдылар. Яңа уку елы укучыларны, балаларны кабаттан очраштырды. Белем бәйрәме - кеше тормышындагы иң зур, дулкынландыргыч һәм шул ук вакытта күңелле дә бәйрәмнәрнең берсе, чөнки ул аларны гомер буе истәлекле хатирә булып озатып бара.

Укучыларның шат авазлары яңгырый, кулларында үзләредәй матур чәчәк бәйләме.




## «Юнармия» сафларына керү

2022 нче елның 10 нчы сентябрендә «ЮНАРМИЯ»Бөтенроссия балалар-яшүсмерләр хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәте сафларына укучыларны багышлау тантанасы булды. Быел 7-10 нчы сыйныф укучылары "яшь армиячеләр" хәрәкәтенә кабул ителде. Бу көнне һәр яшь армиячегә тантаналы ант бирү-һәрвакыт үз Ватаныңа тугъры булу, «Юнармия» уставын үтәү, батырлык, батырлык һәм үзара ярдәмләшү традицияләренә иярү, көчсезләрне яклау, укуда һәм спортта җиңүләргә омтылу, геройларны искә алу хокукы бирелде. Хәрәкәт сафларына керү билгесе итеп, һәр катнашучы кызыл берет алды. Хәрәкәтнең яшь әгъзаларын 9 нчы сыйныфның өлкән иптәшләре озатып йөрде.

Ел саен 1 октябрьдә бөтен илебез Халыкара өлкәннәр көнен билгеләп үтә. Бу көнне барлык өлкәннәргә - сугышта катнашкан каһарманнарыбызга, аннан соңгы авыр елларда илебезне торгызуда фидакарьләрчә хезмәт куйган, имин елларда ил куәтен арттыруга лаеклы өлеш керткән ветераннарыбызга ихтирам белдерү һәм кайгыртучанлык күрсәтү матур традициягә әйләнде. Халыкара өлкәннәр көнендә генә түгел, ветераннарыбызны ел әйләнәсендә игътибар һәм кайгыртучанлык белән җылыту, аларга рухи таяныч булу - безнең олы бурычыбыз.

Хөрмәтле өлкәннәребез! Гомер көзләрегездә урыныгыз түрдән, табыннарыгыз мул, сыйлы ризыкларыгыз бәрәкәтле, җаннарыгыз тыныч, сау-сәламәт булсын. Авыр сугыш елларын горур кичеп, хезмәтне яратып, бүген дә тормыштан тәм табып, яшим дип яшисез. Безгә тыныч, матур тормыш бүләк иткән, авырлыкларда чыныккан иңнәрегез, сабыр җаныгыз бүген дә ил язмышына битараф түгел. Чәчләрегезгә чал керсә дә, сез безнең өчен иң сөйкемле, иң газиз, иң кадерле затлар. Киләчәктә дә алтын киңәшләрегезне биреп, безгә юл күрсәтеп яшәсәгез иде. Һәркайсыгызның гомер көзе җылы, дәвамлы килсен.

КҮКНЕҢ ЖИДЕНЧЕ КАТЫНДА

*Бездә кунакта:* Массакүләм чаралар оештыручы

***Касыймова Диана Мөдәрис кызы***

Сентябрь аенда бездә кунакта Касыймова Диана Мөдәрис кызы булды.

Оештыру эшләре, укучыларны кызыксындырган сорауларга җаваплар, оештыручы эшенең авыр һәм күңелле яклары турында сөйләде.

Эше белән бәйләнешле күңелле мизгелләрне дә искә алып узды.





**“Көзге муллык” күргәзмәсе**

Һәр сентябрь аенда мәктәбебездә “Көзге муллык” күргәзмәсе уздырыла. Әлеге күргәзмәдә укучыларыбызның искиткеч кул эшләрен, аппликацияләрен күрергә була. Укучыларыбыз эшләрен искиткеч бай фантазия белән иҗат иткәннәр. айбер эшләрне газета сөючеләребез, сезгә ә күрсәтеп узабыз.



**Җыр-моң дөньясында...**

3 нче октябрь көнне мәктәбебездә Гүзәл белән улы Гайсә күңелле музыкаль кичә үткәрделәр.

Җанлы музыка, моңлы җырлар, музыкаль тамаша искиткеч күңелле узды. Укучылар рәхәтләнеп биеделәр, җыр-моң дөньясына чумдылар.



**Медицина университеты студентлары бездә кунакта**

Сентябрь аенда МГУ студентлары килеп, 10 нчы сыйныф укучылары өчен күңелле һәм файдалы чара уздырдылар. Укучылар белән кызыклы сорауларга җаваплар таптылар, КВН уздырып, җиңүчеләрне билгеләделәр.

Дзеба Карина

Дзеба Карина
10 нчы сыйныф укучысы

# Игелекле гамәлләр мәктәбе.

Рус әйтеме болай ди: "Кешене кием бизәми , ә яхшы гамәлләре бизи". Яхшы гамәлллләр гасырлардан-гасырларга күчеп, бөтен җир шарында югары бәяләнә. Беркемгә дә сер түгел, яхшы гамәлләр чын йөрәктән чыгып эшләнә. Балачактан безне әби- бабайларыбыз, әти-әниләребез, укытучыларыбыз әйләнә-тирәгә карата яхшы мөгамәләдә, шәфкатьле булырга чакыра. Яхшылык эшләргә мәҗбүр итеп булмый. Хәзерге көндә, табигый һәм техноген катастрофалар, сугыш һәм башка геополитик ситуацияләрдә, кешеләр кырысланды, аларда яхшылык гамәлләре эшләү теләге юк. Тирә-юндә күпме начарлык кылына?!

Мин җәмгыятьне миһербанлыктан башка, якының өчен үз-үзеңне корбан итәргә әзер булучылардан башка, күз алдына китерә алмыйм. Нәрсәнедер үзгәртергә тырышырга кирәк. Мисаллар күрсәтергә кирәк, галәмебезгә яхшылык кертергә өйрәтергә кирәк. Бу эшне кем башкарыр соң?

Шатлыгыбызга, андый кешеләр бар. Берәү генә дә түгел, ә тулы бер мәктәп, Казанның Совет районы 181 нче мәктәбе. Безнең мәктәбебездә ел дәверендә игелекле гамәлләр үткәрелә, анда укучыларыбыз , укытучыларыбыз да битараф калмыйлар. Бу акцияләрдә укытучылар, укучылар, әти-әниләр берләшеп, ярдәмгә мохтаҗларга игелекле эшләр эшлиләр. Һәр елның көз аенда без " Көзге игелекле гамәлләр" атналыгы уздырабыз. Ул үз эченә берничә чараны алып тора: 1) "Игелекләрең белән бүлеш" акциясе. Бу чараны "Игелекле Кешеләр шәһәре" фонды хатына нигезләнеп, укытучылар, әти-әниләр, укучылар алып килгән уенчыклар, балалар ризыклары, йорт кирәк-яраклары һәм башка әйберләр , ДРКБ ның онкология бүлегендә дәваланучылар өчен тапшырыла, 2) "Дүрт аяклыларга ярдәм" акциясе, без хайваннарга ризык җыябыз, 3) "Игелек ярминкәләре", җыелган акчаларны без мөмкинлекләре чикләнгән балаларга тапшырабыз, мәсәлән, без быел ярминкәдә җыелган акчаларны 7 нче номерлы интернат-мәктәбендә укучы , балачактан инвалид Иванов Данил Андреевичка, аны тернәкләндерү өчен тапшырдык, 4) "Китапка икенче тормыш бүләк ит!" акциясе, укучыларыбыз мәктәп китапханәсенә китаплар бүләк итеп, китапханәбезне китаплар белән тулыландыра.

Шулай ук һәр ел, кыш аенда, мәктәбебез " Игелек эшлә" акциясе уздыра. "Бишек" исемендәге ятим балалар йортына, онкологик авыручыларга яңа ел бүләкләре (тәм-томнар, уенчылар, чаңгы һ.б.) тапшыра.

Ярдәмгә мохтаҗ балаларның рәхмәтле йөзләрен күрү ничек рәхәт?! Бу гамәл нинди дә булса билге алу өчен эшләнелми, ә мохтаҗларның шатлыклы йөзен күрү өчен уздырыла. Бу гамәлләрне эшләгәч, "җаның" сөенә, "чәчәк ата".

Яхшы гамәлләр эшләү, тирә-юньдәге кешеләргә, хайваннарга, ярдәмгә мохтаҗларга, аларның борчуларына игътибар итеп булышырга тырышу, җәмгыятебездә уңайлыклар тудыра. Яхшы гамәлләрне эшләү өчен әллә нинди күп көч түгәргә кирәкми, аны төрле урында, төрле очракта эшләргә мөмкин. Юл аркылы чыкканда, өлкәннәргә булышу; иясез хайваннарны һәм кошларны ашату; инвалидларга һәм балалалы хатыннарга урын бирү һ.б. Игелек чылбыр буенча бара, кеше үзенең кеше икәнен онытмаска тиеш.

Игелекле гамәлләрнең нигезендә, һичшиксез, тирә-юньгә мәхәббәт ята. Кеше яхшы гамәл эшләсә, беренче чиратта ул үзен хөрмәт итә башлый, шуның белән ул башкаларга да үрнәк булып тора. Менә мин уйлап торам да, шуны әйтә алам: безнең мәктәбебездә тәрбия эшенең асылын игелеклелек, шәфкатьлелек алып тора.

Иң мөһиме: яхшы гамәлләр эшләү генә түгел, шул эшләрне эшләү теләгән башкаларда уяту да. Бездә барысы да: директордан алып, кечкенә укучыларыбызга кадәр игелек эшләргә тырыша, читтә калмый. Гаиләләре дә бу эшләрдә теләп катнаша. Игелек эшләү, кояш кебек, нурлары җанны җылыта. Игелекле эшләр эшләү дөньяны бизи, ә безне чиста һәм эчкерсез итә.

Игелекле эшләр эшләргә ашыгыгыз!

# КҮКНЕҢ ҖИДЕНЧЕ КАТЫНДА

**Игътибар! Мәктәбебездә президентлыкка сайлау уза. Һәрберегез дә тиешле кандидатка тавышыгызны бирергә онытмагыз!**
**Сайлау көннәре бары 3 көн: 28.09- 30.09.**
**Кандидатларыбыз 3 кыз. Таныш булыгыз!**



**Петрочинина Диана**

***Кредо:***
Сине истә тотарлык итеп яшә!
*Девиз:*
***Күпме кеше,***
***Шулкадәр үк фикерләр***
***Син моңа һичшиксез ЫШАН!***

А.Павлович әйтүенчә, “Кыскалык - һәвәслелек туганы”, шуңа күрә минем яшәешемдә төп аспект, бер сүз белән әйткәндә – иҗат.

Иҗаттан башка тормыш бик күңелсез, “тәмсез” булыр иде. Мин аны берничә көн суыткычка куелган карабодай боткасы белән чагыштырыр идем. Иҗат безнең соры көнебезне буяучы, дип саныйм мин. Уку, рәсем ясау, инша, шигырь язу, видеосъемка, монтаж - болар барысы да тормышыбызны ямьләндерә.

Минем мәктәбебез тормышы турындагы фикерләремә килгәндә, түбәндәгеләрне эшләр идем.Укучыларыбызны күбрәк конференцияләрдә, бәйгеләрдә катнашырга әйдәр идем. “Бу миңа нәрсәгә соң?” дип сораучыларга җавабым: Югары уку йортларына (ВУЗ) кергәндә, ЮНЕСКО грамоталары өчен 10 балл бирелә, бу начармыни?

Әйдәгез, минем белән бергә, мине сайлагыз! Алга атлагыз!

## Камалова Самира




Мин 8 нче сыйныф укучысы. Музыка мәктәбендә укыйм. Төрле бәйгеләрдә, олимпиадаларда катнашам. “Юнармия” хәрәкәте рәтенә кедем. Җаваплы, һәрвакыт куелган максатыма ирешергә тырышам.

- **Сайлау алды программасы:**

1. Фикердәшләрем командасын төзү;
2. Мәктәбебездә булган проблемаларны чишү өчен укучылар, укытучылар арасында аноним сораулар уздыру;
3. Бөтен проблема, теләкләрне искә алып программа төзү;
4. Төрле һөнәр ияләре : музыкантлар, актерлар, кондитерлар, менеджерлар h.б. белән очрашулар уздыру ;
5. Һәрвакыт төгәл булу.

Миңа тавыш бирегез! Минем белән булыгыз!



## Панарина Алинә

Мин - Панарина Алинә. Миңа 15 яшь, 9 нчы «А» сыйныфында укыйм. Мин бик җаваплы, ышанычлы, иҗади кеше. Һәр кешегә ярдәм итәргә һәрвакыт әзер.

Минем максатым:укучыларга үзләренең киләчәге турында уйланып, дөрес юлны сайларга булышу, мәктәп еллары аларга шатлык кына китерсен өчен тырышу.

Минем кредо: әгәр дә син тырышмасаң, максатыңа ирешә алмасссың.

Һәр кешенең тормышында киләчәк һөнәрне дөрес сайлау тора, бу эш җиңел түгел. Президент статусы миңа мәктәп тормышын төрлеләндерергә, аларга булачак һөнәрләрен сайлаганда ярдәм итәргә мөмкинчелек тудырачак.

Мине сайлагыз! Минем белән булыгыз!

**Редакциянең адресы:**420101, Казан шәһәре, Тулпар урамы, 2

Тел. 89050229576 **Тираж** – 50 экз.

**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Габдуллаҗанова А.Ф.

**Редколлегия әгъзалары:**
Соколова София, Овезова Ләйлә, Сафина Камилла, Дзеба Карина